| | |
|---|---|
| **Республика Татарстан**<br>**Совет Шарлиареминского**<br>**сельского поселения**<br>**Сармановского муниципального**<br>**района** | **Татарстан Республикасы**<br>**Сарман муниципаль районы**<br>**Шәрләрәмә авыл җирлеге**<br>**Советы** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

24 ноябрь 2023 ел № 84

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегенең 2024 нче елга һәм 2025, 2026 нче план еллар чорына бюджеты турында карар проекты турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Шәрләрәмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Шәрләрәмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Кушымта нигезендә «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегенең 2024 елга һәм 2025, 2026 елларның план чорына бюджеты турында» карар проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Әйтелгән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып, аның өстендә эшне дәвам итәргә.

3. Татарстан Республикасы Министрләр Кабинетының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегенең 2024 елга һәм 2025, 2026 еллар план чорына бюджеты турында » карар проектына кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча түбәндәге составта эшче төркем оештырырга:

1. Хуҗина Н.Н. – төркем җитәкчесе
2. Ахметшина Р.Ф. – төркем әгъзасы
3. Гайнетдинова Р.Р.– төркем әгъзасы
4. Халиуллина С.А.- төркем әгъзасы
5. Салихҗанова М.Р.- төркем әгъзасы

4. Карар проектына гражданнарның тәкъдимнәре ТР, Сарман муниципаль районы,Шәрләрәмә авылы, Мәктәп урамы, 57 йорт адресына язмача җибәрелә дип билгеләргә.

5. Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегенең 2024 нче елга һәм 2025, 2026 нче елларның планлы чорына бюджеты турындагы карар проекты буенча ачык тыңлауларны 2023нчы елның 6 нче декабрендә 14.00 сәгатьтә билгеләргә.

6. Эшче төркемгә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге Советы депутатлары төзәтмәләрен һәм карар проектына гражданнарның тәкъдимнәрен өйрәнергә һәм гомумиләштерергә, карар проектын эшләп бетерергә һәм аны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге Советы каравына 2023 елнын 14 декаберенә кадәр кертергә.

7. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» (PRAVO TATARSTAN .RU) һәм Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы»

муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Шәрләрәмә авыл җирлеге
Советы рәисе Н.Н.Хуҗина

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге Советының 2023 нчы елның 24 нче ноябрендә кабул ителгән 84 нчы номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегенең 2024нче елга һәм 2025, 2026 нче еллар план чорына бюджеты турында карар

1 Статья

1. Шәрләрәмә авыл җирлеге Сарман муниципаль районының 2023 елга бюджетынын төп характеристикасын расларга:

1) Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге бюджетының фаразланган гомуми керем күләме 4729,2 мең сум күләмендә;

2) Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге бюджетының гомуми чыгымнары күләме 4729,2 мең сум.;

3) Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге бюджеты кытлыгы 0,0 мең сум.

2. Шәрләрәмә авыл җирлеге Сарман муниципаль районының 2025 елга һәм 2026 елга бюджетынын төп характеристикасын расларга:

1) Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегенең 2025 елга фаразланган кеременең гомуми күләме 4849,7 мең сум һәм 2026 елга 4956,5 мең сум күләмендә.;

2) Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге бюджетының 2025 елга гомуми чыгымнары күләме 4849,7 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 122 мең сум күләмендә, һәм 2026 елга 4956,5мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар-248,00 мең сум күләмендә.;

3) Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге бюджеты кытлыгы 2025 елга 0,0 мең сумга һәм 2026 елга 0,0 мең сумга.

3. Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегенең 2024 нче елга һәм 2025, 2026 нче еллар план чорына бюджет кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә расларга.

2 Статья 2 Статья

1. 2025 елның 1 гыйнварына Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегенең Эчке муниципаль бурычының югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегенең муниципаль гарантияләре буенча бурычының югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга.

2. 2026 нче елның 1 нче гыйнварына Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегенең Эчке муниципаль бурычының югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегенең муниципаль гарантияләр буенча бурычының югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга.

3. 2027 нче елның 1 нче гыйнварына Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегенең Эчке муниципаль бурычының югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегенең муниципаль гарантияләр буенча бурычының югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга.

3 Статья

Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге бюджетында 2024 нче елга һәм 2025, 2026 нче еллар план чорына фаразланган керем күләмен исәпкә алырга.

4 Статья

1.Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге бюджетының 2024 елга һәм 2025, 2026 еллар план чорына керемнәрен бүлү нормативларын расларга, әлеге карарның 3 нче кушымтасы нигезендә, карар кабул ителде.

2. Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге бюджеты керемнәренең Баш администраторлары исемлеген әлеге карарның 4 нче кушымтасы нигезендә расларга.

3. Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының Баш администраторлары исемлеген шушы карарның 5 нче кушымтасы нигезендә расларга.

4. Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге бюджетының 2024 елга халык алдында норматив йөкләмәләрне үтәүгә юнәлдерелә торган бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 2025 елга-0,0 мең сум, 2026 елга 0,0 мең сум күләмендә расларга.

5 Статья

1.Шәрләрәмә авыл җирлеге бюджетыннан 2024 елга, төзелгән килешүләр нигезендә, мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял оештыру өчен шартлар тудыру буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен 2747,6 мен сум , 2025 елга 2786,7 мең сум күләмендә, 2026 елга 2828,8 мең сум күләмендә башка бюджетара трансфертлар күләмен раслау

2. 2024 елда Шәрләрәмә авыл җирлеге бюджетыннан башка бюджетара трансфертларны күчерү ай саен тигез өлешләр белән башкарыла дип билгеләргә кирәк.

6 Статья

Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге бюджетында Сарман муниципаль районы бюджетыннан алына торган акчаны исәпкә алырга:

1) 2024 елга бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр-3936,4 мең сум, 2025 елга-4051,1 мең сум, 2026 елга-4151,9мең сум.;

2) 2024 елга хәрби комиссариатлары булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру өчен авыл җирлекләре бюджетларына субвенцияләр-0 мең сум, 2025 елга-0 мең сум, 2026 елга-0 мең сум.

7 Статья

Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге җирле үзидарә органнары 2024 елда муниципаль хезмәткәрләр, шулай ук муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләре санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

8 Статья

2024нче елның 1 нче гыйнварына Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге исеменнән 2023 нчы елда бу муниципаль контрактларның шартлары нигезендә Товарлар белән тәэмин итүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль контрактларның Шәрләрәмә авыл җирлеге исеменнән төзелгән, файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләренең калдыгы суммасыннан артмаган күләмдә Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге бюджеты акчасы калдыклары 2024 нче елның 1 нче гыйнварына, 2023нче елда Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге башкарма комитеты тиешле карар кабул иткән очракта, әлеге максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.

9 Статья

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары төзелгән килешүләр нигезендә Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыралар.

10 Статья

Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» (PRAVO TATARSTAN .RU) һәм Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.

11 Статья

Әлеге карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

12 Статья

Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Шәрләрәмә авыл җирлеге
Советы рәисе Н.Н.Хуҗина